КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 6 февраль г.Казань № 61

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында ирекле хәрәкәткә булышлык күрсәтү турында» 2012 ел, 5 октябрь, 830 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында ирекле хәрәкәткә булышлык күрсәтү турында» 2012 ел, 5 октябрь, 830 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 13 июль, 510 нчы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Ихтыяри затларның (волонтерларның) шәхси кенәгәсе турындагы нигезләмәне раслау турында»;

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Бу карарга теркәлгән Ихтыяри затларның (волонтерларның) шәхси кенәгәсе турындагы нигезләмәне расларга.»;

3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгына йөкләргә.»;

әлеге карар белән расланган Ихтыяри затларның (волонтерларның) шәхси кенәгәсе турындагы нигезләмәдә:

түбәндәге эчтәлекле 1.3 һәм 1.4 пунктлар өстәргә:

«1.3. Ихтыяри зат (волонтер) үз теләге белән Кенәгә алырга хокуклы.

1.4. Ихтыяри затның (волонтерның) хокуклары һәм бурычлары «Хәйрия эшчәнлеге һәм ихтыярилык (волонтерлык) турында» 1995 елның 11 августындагы 135-ФЗ номерлы Федераль законның $17^1$ статьясында билгеләнгән.»;

4 пунктта «Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы» сүзләрен «Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы» сүзләренә алмаштырырга;

2.2 пунктта «(учреждениене)» сүзен төшереп калдырырга;

2.3 пунктта «14 яше» сүзләрен «сигез яше» сүзләренә алмаштырырга;

2.4 пунктта:

беренче абзацта «түбәндәге документларны тапшырырга кирәк» сүзләрен «граждан, аның законлы вәкиле яки граждан тарафыннан ышанычнамә нигезендә аның исеменнән эш итәргә вәкаләтле зат түбәндәге документларны тапшыра» сүзләренә алмаштырырга;

өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Министрлык боерыгы белән расланган форма буенча шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә гражданның ризалыгы;»;

дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3 х 4 сантиметрлы бер төсле фотосурәт (сурәт төгәл булырга, яктылык таплары һәм кечкенә вак рәсемнәр, ясалма кимчелекләр булмаска тиеш, шулай ук йөзнең пластикасын матурлау тыела, фон ак һәм (яки) якты, бертөсле, фонда күләгәләр, бозулар, ерыклар тыела, төгәл туры караш);»;

бишенче абзацта «ата-аналарның (опекунның)» сүзләрен «законлы вәкилнең» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«гражданның шәхесен таныклый торган документ күчермәсе;

шәхесне таныклый торган документ һәм законлы вәкилнең яки граждан тарафыннан ышанычнамә нигезендә аның исеменнән эш итәргә вәкаләт бирелгән затның вәкаләтләрен раслый торган документ күчермәсе.»;

2.5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.5. Вәкаләтле оешма документлар кабул ителгән көннән алып 10 көн эчендә:

әлеге Нигезләмәнең 2.4 пунктында күрсәтелгән документларның күчермәләрен Министрлыкка җибәрә;

әлеге Нигезләмәгә 4 нче кушымтада бирелгән форма буенча Кенәгәләр бирү реестрын тутыра, әлеге Нигезләмәгә 5 нче кушымтада бирелгән форма буенча Кенәгәгә кертү өчен чаралар планын булдыра һәм аларны электрон төрдә dobrotatarstan@yandex.ru электрон почтасына җибәрә.

Әлеге Нигезләмәнең 2.4 пунктында күрсәтелгән документларның төп нөсхәләре вәкаләтле оешма тарафыннан ике ел дәвамында саклана.»;

2.7 пунктта:

икенче абзацта «атасының исеме» сүзеннән соң «(булганда)» сүзләрен өстәргә;

дүртенче абзац үз көчен югалткан дип танырга;

сигезенче абзацта «, спорт һәм туризм» сүзләрен төшереп калдырырга;

3.1 пунктта «Ихтыяри хәрәкәт (волонтерлык) эшчәнлеге турында язмалар» сүзләреннән соң «(алга таба – язма)» сүзләрен өстәргә, «(учреждениеләр)» сүзен төшереп калдырырга;

3.2 пунктта «(учреждение)» сүзен төшереп калдырырга;

3.3 пунктта:

беренче абзацта «(учреждениеләр)» сүзен төшереп калдырырга;

икенче абзацта «(учреждениеләр)» сүзен төшереп калдырырга, «Татарстан Республикасы Экология министрлыгына» сүзләрен «Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгына» сүзләренә алмаштырырга, «Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгына» сүзләрен «Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгына» сүзләренә алмаштырырга;

өченче абзацта «(учреждениеләр)» сүзен төшереп калдырырга;

алтынчы абзацта «(учреждениеләр)» сүзен төшереп калдырырга;

3.4 пункт үз көчен югалткан дип танырга;

4.3 пунктта:

икенче абзацта «атасының исеме» сүзеннән соң «(булганда)» сүзләрен өстәргә;

өченче абзац үз көчен югалткан дип танырга;

V бүлек исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«V. Республика башкарма хакимият органнары вәкаләтләре»;

5.1 пунктта:

өченче абзацта «әзерли» сүзен «әзерләүне тәэмин итә» сүзләренә алмаштырырга;

дүртенче абзацта «Кенәгәләрне рәсмиләштерүне тәэмин итә» сүзләрен «Кенәгәләрне рәсмиләштерә» сүзләренә алмаштырырга;

5.2 пунктта:

беренче абзацта «(учреждениеләргә)» сүзен төшереп калдырырга;

дүртенче абзацта «ихтыяри затлар вакансияләре» сүзләрен «ихтыярый затлар (волонтерлык) эшчәнлеге чаралары (алга таба – чаралар) турында мәгълүмат» сүзләренә алмаштырырга;

бишенче абзацта «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга, «, учреждениеләр» сүзен төшереп калдырырга, «ихтыяри затлар (волонтерлар) вакансияләре» сүзләрен «чаралар» сүзенә алмаштырырга;

алтынчы абзацта «ихтыяри затлар (волонтерлар) вакансияләре» сүзләрен «чаралар» сүзенә алмаштырырга;

җиденче абзацта «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга, «учреждениеләр» сүзен төшереп калдырырга;

5.3 пунктта «ихтыяри затлар (волонтерлар) вакансияләре» сүзләрен «чаралар» сүзенә алмаштырырга, «Татарстан Республикасы Экология министрлыгы» сүзләрен «Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы» сүзләренә алмаштырырга;

6.1 пунктта:

дүртенче абзацта «ихтыяри затлар вакансияләре» сүзләрен «чаралар турында мәгълүмат» сүзләренә алмаштырырга;

бишенче абзацта «ихтыяри затлар (волонтерлар) вакансияләре» сүзләрен «чаралар» сүзенә алмаштырырга;

алтынчы абзацта «, учреждениеләр» сүзен төшереп калдырырга;

VII бүлек исемендә «(учреждениеләр)» сүзен төшереп калдырырга;

7.1 пунктта:

беренче абзацта «(учреждениеләр)» сүзен төшереп калдырырга;

икенче абзацта «ихтыяри затлар (волонтерлар) вакансияләре» сүзләрен «чаралар» сүзенә алмаштырырга;

VIII бүлек үз көчен югалткан дип танырга.

9.1 пунктта:

өченче абзацта «учреждениеләр» сүзен «оешмалар» сүзенә алмаштырырга;

алтынчы абзац үз көчен югалткан дип танырга;

9.2 пунктта «9.1 пункты» сүзләрен «әлеге Нигезләмәнең 9.1 пункты» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге Нигезләмәгә 1 нче кушымта «Ф.И.Ат.ис.» аббревиатурасыннан соң «(соңгысы – булганда)» сүзләрен өстәргә;

әлеге Нигезләмәгә 2 нче кушымтаны үз көчен югалткан дип танырга;

әлеге Нигезләмәгә 3 нче кушымтаның 4, 5, 6, 8, 14, 15 пунктлары үз көчен югалткан дип танырга;

әлеге Нигезләмәгә 4 һәм 5 нче кушымталар (карарга теркәләләр) өстәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Ихтыяри затның (волонтерның) шәхси кенәгәсе турында нигезләмәгә 4 нче кушымта
(Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 ел, 6 февраль, 61 нче карары редакциясендә)

Форма

Ихтыяри затның (волонтерның) шәхси кенәгәләрен бирү реестры

| Ихтыяри затның (волонтерның) Ф.И.Ат.ис. (соңгысы – булганда) | Туган көне | Белеме/квалификациясе | Уку/эш урыны | Ихтыяри затның (волонтерның) шәхси кенәгәсен бирү датасы һәм номеры | Телефон номеры | Шәхесне таныклый торган документның мәгълүматы (серия, номер, кем тарафыннан һәм кайчан бирелгән) | Ихтыяри затлар (волонтерлар) эшчәнлегенең исеме һәм төре (конкрет чара) | Чара датасы | Чараны үткәрү урыны | Эшләнгән сәгатьләр саны |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | | | |

____________________________

Ихтыяри затның (волонтерның) шәхси кенәгәсе турында нигезләмәгә 5 нче кушымта (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 ел, 6 февраль, 61 нче карары редакциясендә)

Форма

Ихтыяри затның (волонтерның) шәхси кенәгәсенә кертү өчен чаралар планы

| Муниципаль берәмлек исеме | Чараның исеме | Чараны үткәрү датасы | Чараның тасвирламасы | Үткәрү урыны, планлаштырыла торган колачлау | Җәлеп ителә торган ихтыяри затлар (волонтерлар) саны |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |